


Башкалабыз Пресс-Үзәгендә Рос-сиянен атказанган артисты Любовь Николаевна Руденко, «Квадратный телевизор» генераль продюсеры Оксана Владимировна Матвеева һәм «Мир и гармония» Хәйрия (благотворительный) Фонды житәкчесе Эльмира Муратбек кызы Щербакова белән очрашу оештырылган иде.
Эльмира Муратбековна - «Театральная Россия» мәдәни-социаль проект идеясе авторы һәм генераль продюсеры. Проект оч ел элек донья кvргән. Топ кызыгы - кинода театр. Югары тизлектәге интернет һәм бvгенге технологияләр турыдан-туры Мәскәv һәм Санкт-Петербург коллективларынын ин әйбәт спектакльләрен илебезнен торле шәһәрләре кинотеатрларындагы кин экраннарында онлайн кvрсәтv момкинлеген тудыра.
Әйтеп китәргә кирәк, Эльмира Щербакова Саранскка килергә кvптән хыялланган. Монын сәбәбе тvбәндә. Эльмира яшvсмер чагында «Артек» балалар ял лагеренда Саранск шәһәреннән Дима дигән малай белән бергә ял итә һәм дусты туган шәһәренен матурлыгын истә калырлак иттереп сойли. Эльмира дустынын Саранск шәһәрен килеп карарга дигән максат куя. Хыялын чынга ашырырга «Театральная Россия» ярдәм итә. Чыннан да, Саранск шәһәре vзенен кешеләре, архитектурасы, яна театрлары, чисталыгы белән әлеге проект житәкчесенә бик тә ошый.
Шулай итеп, 4 декабрьдә Саранскнын «Россия» киноvзәгендә режиссёр Глеб Черепанов белән куелган «Тургенев. Сегодня» биографик спектакльнен онлайн трансляциясе булачак. Бу авторнын 200-еллык юбилеена багышланган. Тургеневны атаклы артист Анатолий Руденко уйный, башка персонажларны - Мәскәv театры актёрлары һәм Олег Табаковнын Театр мәктәбе студентлары. Әйтеп китәргә кирәк, Эльмира Щербакова vзен Олег Павловичнын укучысы дип саный. Берничә ел элек, театрнын һәрбер социаль катлам кешесенә ачык булуы, бигрәк инвалидларга, Э.М.Щербакованын шул идеясен Табаков укытучысы хуплады. Һәм нәкъ О.П. Табаков житәкләгән А.П. Чехов исемендәге МХТ спектакльләре беренче буларак «Театральная Россия» проекты афишасына эләгә. Бу проект бездә яшиячәк. Шулай ук якташларыбыз Николай Чиндяйкин, Станислав Дужников, Игорь Марычев уйнаган театраль спектакльләрен дә кvрсәтерләр.

**Н.Хәлил**